**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.09.2016 Балык Бистәсе штп. № 157пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38п номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы каршындагы Коррупциягә каршы тору комиссиясен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенә үзгәртеп коруга һәм Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору өлкәсендә эшчәнлекне оештыруны камилләштерү чаралары турында» 2015 елның 15 июлендәге 364 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе турында»2015 елның 13 октябрендәге ПУ-986 номерлы Указы басылуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы каршындагы Коррупциягә каршы тору комиссиясен үзгәртеп коруга бәйле, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгының 2015 елның 10 декабрендә кабул ителгән 144пг номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе турында» карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган «2015-2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 31 маендагы 80пи номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.программа паспортында:

а)таблицада «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе»сүзләренә алмаштырырга;

б) «I. Программаны тормышка ашыру сферасының гомуми характеристикасы, проблемалар һәм аларны хәл итү юллары»бүлегендә:

дүртенче абзацта " коррупциягә каршы тору буенча район башлыгы каршындагы комиссия" сүзләрен "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта "Коррупциягә каршы тору буенча район башлыгы каршындагы комиссия" сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе " сүзләренә алмаштырырга;

в) «IV.Программаны тормышка ашыру механизмы»:

беренче абзацта " коррупциягә каршы тору буенча район башлыгы каршындагы комиссия" сүзләрен "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта " коррупциягә каршы тору буенча район башлыгы каршындагы комиссия секретаренә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе секретаренә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта "Коррупциягә каршы тору буенча район башлыгы каршындагы комиссия" сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе " сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

"Программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан һәм нәтиҗәле тотылышын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Контроль-хисап палатасы гамәлгә ашыра (килешү буенча).»;

унынчы абзацны унберенче абзац дип санарга;

г) "2015-2020 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау» кушымтасында:

1.3 пунктта "коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча район башлыгы каршындагы комиссия" сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе " сүзләренә алмаштырырга;

5.10 пунктта. «коррупциягә каршы тору комиссиясе"сүзләрен «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында

коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга;

9.7 пунктында. «коррупциягә каршы тору комиссиясе "сүзләрен «коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү комиссиясе" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин